**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**<u>Сарман авыл җирлеге</u>**
**423350 Сарман авылы, Ленин ур., 28**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sarman-SP @ rambler.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**<u>Сармановское сельское поселение</u> САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.Ленина, 28**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sarman-SP @ rambler.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 25 25 ноябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына бюджеты турында карар проекты турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:
1. Кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 елларның план чорына бюджеты турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында » карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:

1. Нуруллин Р. Р. – төркем җитәкчесе;
2. Мөхәммәдиев Р. Ә– - төркем әгъзасы;
3. Сәлимгәрәев Р.Ф. – төркем әгъзасы.

4. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре, авторның туган елы, адресы: ТР, Сарман муниципаль районы, Сарман авылы, Ленин урамы, 52 йорт, т. 2-45-38 күрсәтелгән, язмача төркемгә җибәрелә дип билгеләргә.
5. Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче елларның планлы чорына бюджеты турындагы карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2019 нчы елның 5 нче декабрендә 15.00 сәгатьтә билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советы каравына 2019 елнын 5 декаберенә кадәр кертергә.
7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

8.  Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Сарман авыл җирлеге карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Сарман Муниципаль Районы Советы Рәисе
авыл җирлеге башлыгы
муниципаль район башлыгы Ф. М. Хөснуллин